**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

№ 58-444

2025 елның 18 июленнән

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкы өчен 2024 елда амбулатор-сырхауханә ярдәменнән һәркем файдалана алырлык булуы һәм үсеш перспективалары һәм 2025 елга бурычлар турында

Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы вазыйфаларын башкаручы Н.А. Романская Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкы өчен 2024 елда амбулатор-сырхауханә ярдәменнән һәркем файдалана алырлык булуы һәм үсеш перспективалары һәм 2025 елга бурычлар турындамәгълүматларын тыңлап, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкы өчен 2024 елда амбулатор-сырхауханә ярдәменнән һәркем файдалана алырлык булуы һәм үсеш перспективалары һәм 2025 елга бурычлар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә:

- инвалидлыкны һәм үлем-төшемнәрне киметү максатында амбулатория-поликлиника медицина ярдәме күрсәтүнең мөмкинлеген, культурасын һәм сыйфатын яхшырту буенча даими эш алып барырга;
- беренчел медицина-санитария ярдәмен үстерү буенча алга таба эш алып барырга, шул исәптән диагностика һәм дәвалауның заманча ысулларын да кертеп;
- дәвалау учреждениеләре һәм фельдшер-акушерлык пунктлары инфраструктурасын яхшыртуны һәм цифрлаштыруны, яңа технологияләрне тагын да активрак гамәлгә кертергә;
- поликлиникаларның матди-техник базасын арттыру, шулай ук медицина хезмәткәрләрен укыту һәм квалификацияләрен күтәрү өстендә эш алып барырга;
- табиб кадрларын җәлеп итү буенча эшне активлаштырырга;
- халык өчен амбулатория-поликлиника ярдәме эшчәнлегендә профилактик юнәлешне көчәйтергә.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан РеспубликасыЯңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә фармэшчәнлек буенча фельдшер-акушерлык пунктларын лицензияләү эшен дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары Н.И.Попкова